ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» 06 2021 ел. № 145

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы дәүләт органнарында дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрларын Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 12 февралендәге УП-132 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт органнарында дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрларын Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару эшчәнлеген камилләштерү максатларында Балтач муниципаль районы башлыгы **карар бирә:**

1. Балтач муниципаль районы башлыгының 2016 елның 5 августындагы 139 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 5 пунктында «, шулай ук кәгазь чыганакта» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. Нигезләмәнең 6 пунктында «кәгазь чыганакта» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. Нигезләмәнең 7 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

1.4. Нигезләмәнең 8 пунктында «Департамент тарафыннан» сүзен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар Департаменты (алга таба - Департамент) тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 11 пунктның икенче абзацында «атасының исеме» сүзеннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

1.6. Нигезләмәнең 21 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре реестрлары, аларга кертелгән үзгәрешләр, алардагы мәгълүматны, аларда булган мәгълүматны рөхсәтсез файдаланудан, юкка чыгарудан, модификацияләүдән, ябудан, күчермә ясаудан, бирүдән, таратудан, шулай ук башка хокуксыз гамәлләрдән яклауны тәэмин итеп, Мәгълүмат системасында саклана.»;

1.7. Нигезләмәнең 22 һәм 23 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар үз көченә кергәнче кәгазь чыганакларда төзелгән Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре реестрлары аларга рөхсәтсез файдалану мөмкинлеген юкка чыгара торган режимда аларны төзегән көннән алып 5 ел дәвамында (катгый хисап документлары буларак) саклана, шуннан соң Россия Федерациясе законнары нигезендә архивка саклауга тапшырыла.

3. Әлеге карар имза куелган көннән үз көченә керә.

Балтач муниципаль
районы башлыгы Р.Р. Нотфуллин